ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 156-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Р. Зарипов, Р.Җ. Мөхәммәтшина, М.Х. Сәлахов, И.В. Терентьева тарафыннан кертелгән «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 156-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 544-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Р. Зарипов,
Р.Җ. Мөхәммәтшина,
М.Х. Сәлахов,
И.В. Терентьева
тарафыннан кертелә

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 33 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) $15^2$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$15^2$) Федераль законның $71^1$ статьясындагы 6 өлешендә каралган компенсация түләү тәртибен, аның күләмен билгеләү һәм аны Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибен билгеләү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $15^2$ пункт өстәргә:

«$15^4$) Федераль законның $71^2$ статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә каралган штраф түләү тәртибен, Федераль законның $71^2$ статьясындагы 5 өлешендә каралган компенсация түләү тәртибен, аларның күләмнәрен билгеләү һәм аларны Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибен билгеләү;»;

2) 17 статьяның 2 өлешендә:

а) беренче абзацта «үткәрүне һәм» сүзләрен «үткәрүне,» сүзенә алмаштырырга, «кабул итүне» сүзләреннән соң «, шулай ук югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар студентларының студент билетлары

турында һәм зачет кенәгәләре турында белешмәләр, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары, аспирантурада фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча укуны раслый торган башка документлар турында белешмәләрне бирүне» сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктта «үткәрүне һәм» сүзләрен «үткәрүне,» сүзенә алмаштырырга, «кабул итүне» сүзләреннән соң «, шулай ук югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар студентларының студент билетлары турында һәм зачет кенәгәләре турында белешмәләр, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары, аспирантурада фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча укуны раслый торган башка документлар турында белешмәләрне бирүне» сүзләрен өстәргә;

3) 20 статьяда:

а) 1 өлештә «граждан» сүзен «Россия Федерациясе гражданы, әгәр Федераль законда яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса,» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «күләмендә» сүзеннән соң «эшкә урнаштыру буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә максатчан укыту турында шартнамәне берьяклы тәртиптә өзгән өчен» сүзләрен өстәргә;

в) 7 өлештә «компенсацияне түләү» сүзләрен «эшкә урнаштыру буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә максатчан укыту турында шартнамәне берьяклы тәртиптә өзгән өчен компенсация түләү» сүзләренә алмаштырырга, «бердәм порталы аша бирү тәртибе» сүзләреннән соң «, максатчан укыту турында яңа шартнамә төзү тәртибе» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 3 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 3 пунктлары 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законын 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керәчәк «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 17 ноябрендәге 424-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – 424-ФЗ номерлы Федераль закон), аның 3 статьясыннан тыш, һәм 2025 елның 29 декабрендә үз көченә кергән «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 539-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – 539-ФЗ номерлы Федераль закон) туры китерү максатларында эшләнде.

Россия сәламәтлек саклау системасындагы кадрлар кытлыгы мәсьәләсен хәл итү максатларында кабул ителгән 424-ФЗ номерлы Федераль закон белән шулай ук «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелә. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына максатчан укыту турында шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен штраф һәм компенсация түләү, аларның күләмнәрен билгеләү һәм аларны тиешле бюджетка күчерү тәртибен билгеләү өлешендә яңа вәкаләтләр бирелә.

539-ФЗ номерлы Федераль закон белән шул исәптән югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар студентларының студент билетлары турында һәм зачет кенәгәләре турында белешмәләр, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары, аспирантурада фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча укуны раслый торган башка документлар турында белешмәләр (алар булган очракта) югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар тарафыннан федераль мәгълүмат системасына тапшырыла.

Моңа бәйле рәвештә «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү «Югары белем бирүнең уку-укыту программалары буенча Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән максатчан укыту турында шартнамә буенча йөкләмәләрне үтәмәгән өчен штраф түләү тәртибен, аның күләмен билгеләү һәм аны Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 30 мартындагы 248 номерлы карарына үзгәреш кертү таләп ителә.

**«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.